**РАСЛЫЙМ**
24 нче балалар бакчасы мөдире
_________ А.А. Мәрдәнова
«__31__»__08______2022 ел

**Казан шәһәре Вахитов районы МБМБУ « 24 нче балалар бакчасы»**
**кечкенәләр төркемендә тәрбия һәм белем бирү проектларын**
**тормышка ашыру буенча**
**2022-2023 уку елына перспектив-тематик план**

| Тема | Эшчәнлек эчтәлеге | Вакыты | Йомгаклау чаралары |
|---|---|---|---|
| **«МИН ҺӘМ БАКЧА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Исәнме, бакча!<br><br>Безнең төркем | Балаларны балалар бакчасы, бакча хезмәткәрләре, мөхите, кагыйдәләре белән таныштыру. Башка балалар белән танышу. Төркемдәге иптәшләре белән дустанә мөнәсәбәт урнаштыру, үзара уеннар оештыру, уйнау. | 1-9 сентябрь | Яңа килгән балалар белән әңгәмәләр, танышу уеннары уйнау “Әйдәгез, танышабыз” Экскурсия “Бакча” |
| Бакчадагы уңыш | Балаларның яшелчәләр, җиләк-җимешләр турындагы белемнәрен киңәйтү. Бакча түтәлендә өлгергән уңышны күзәтү, аны җыеп алуны оештыру. | 12-16 сентябрь | Күмәк хезмәт “Уңыш җыябыз” |
| Сак җәяүле атналыгы | Транспорт һәм аның төрләре турында белем бирү. Шәһәр объектлары (урам, йорт, биналар), урам, юл турында сөйләшү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча белемнәрне үстерү, светофордан һәм юл билгеләреннән дөрес итеп файдалана белү күнекмәсен ныгыту, активлык, игътибарлылык тәрбияләү. | 19-23 сентябрь | **Әңгәмә:** «Нинди машиналар бар?», «Нәрсә ул – светофор?», «Юл йөрү билгеләре нигә кирәк». **Әдәбият уку:** Б.Рәхмәт “Көпчәкле атлар” , В. Семерин «Запрещается – разрешается». **Уеннар** : “Тупны тегәрәтә бел”, “Светофор” |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **«ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ. КӨЗ ТӨСЛӘРЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Хайваннар дөньясы<br><br>4 октябрь – Бөтендөнья хайваннарны яклау көне | Балалар һәм хайваннар: хайваннар белән үзеңне ничек тотарга, нинди куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә темаларына профилактик әңгәмәләр үткәрү.<br>Хайваннар турында белемнәр формалаштыру, аларның төрләре һәм яшәү тирәлекләре белән якыннанрак танышу.<br>Хайваннарга карата игътибарлы мөнәсәбәт һәм мәхәббәт тәрбияләү. | 3 – 7 октябрь | Тематик альбомнар, журналлар һәм китаплар карау.<br>«Яхшылык кыл» **акциясендә катнашу** (сукбай хайваннар приюты өчен азык җыю) |
| Шәһәр парклары. Агачлар һәм куаклар. | Табигатьтәге һәм шәһәр паркларындагы үзгәрешләрне күрергә өйрәтү.<br>Балаларның көз турындагы күзаллауларын киңәйтү (табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, кешеләрнең киемнәре,балалар бакчасы ишегалды, парклар һәм аллеялар).<br>Табигатьтә үз-үзеңне имин тоту кагыйдәләре белән таныштыру. | 10-14 октябрь | «Көзге прогулка» **фотовыставкасы** (ата-аналар белән эш) |
| **3 - 14 октябрь - ПЕДАГОГИК ПРОЦЕСС МОНИТОРИНГЫ** | | | |
| Табын күрке - икмәк | Балаларның икмәк һәм камыр ризыклары турында күзаллауларын киңәйтү. Икмәккә карата сакчыл караш; хезмәт кешеләренә (игенчеләр, пешекчеләр, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә) карата ихтирам тәрбияләү. | 17-21 октябрь | «Икмәк һәм камыр ризыклары» **альбомы ясау** |
| Алтын көз | Балаларның көз ел фасылы турында күзаллауларын киңәйтү. Көзге табигатьнең матурлыгын күрү сәләтләрен үстерү, һава торышын күзәтү.<br>Балаларда бәйрәм кәефен булдыру өстендә эшләү, төркемне Сөмбелә бәйрәменә бизәү.<br>Үзара игътибарлы һәм дустанә мөнәсәбәт булдыру. | 24-28 октябрь | «Сөмбелә» **бәйрәме** |
| **«ВАТАН НӘРСӘДӘН БАШЛАНА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Халыклар бердәмлеге көне | Төркемне бәйрәмгә бизәү: дәүләт символикалары белән танышу. Балалар яшәгән шәһәр, урам исемнәрен искә төшерү.<br>Шәһәр иллюстрацияләрен игътибар белән карау һәм сорауларга җавап бирү күнекмәләрен үстерү.<br>Дуслык турында әңгәмә.<br>Идел буенда яшәүче халыклар турында беренчел белемнәр бирү (татарлар, руслар, чувашлар, удмуртлар, марийлар һ.б.) | 31 октябрь-4 ноябрь | «Этномәдәни региональ состав» **почмагын бизәү**<br><br>**Идел буе халыкларының уеннары һәм уенчыклары** |
| Нәрсә ул яхшылык?<br><br>13 ноябрь – Бөтендөнья яхшылык көне | Балаларда яхшы тон, этикет сыйфатларын формалаштыру. Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт хисләрен үстерү. Үзара ярдәмләшергә, яхшы эшләр эшләргә өйрәтү.<br>Кешелеклелек, үзара ихтирам хисләрен тәрбияләү. | 7-11 ноябрь | **12 ноябрь – Песнәк көне (фотога төшерү)**<br>«Кәгазь җыеп тапшыр һәм урманны саклап кал!» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | **экоакциясендә катнашу** |
| Сәламәт тәндә – сәламәт акыл | Балаларда сәламәт яшәү рәвеше алып бару турында кузаллау булдыру. Балаларга файдалы һәм зыянлы азык-төлек һәм гадәтләр турында белемнәр бирү. Үз сәламәтлекләре хакында уйларга һәм кайгыртырга өйрәтү. | 14-18 ноябрь | «Сәламәт яшәү рәвеше алып бару кагыйдәләре» темасына консультацияләр, буклетлар, мәгълүмати стендлар әзерләү |
| Мин һәм минем гаиләм.<br><br>Бөтендөнья бала көне.<br><br>Россиядә әниләр көне. | Гаилә, әнигә мәхәббәт темаларына карата барлык эшчәнлек төрләрен дә оештыру. Җенесләр турында күзаллау формалаштыру. Балаларны үз исемнәрен һәм гаилә әгъзаларының исемнәрен әйтергә өйрәтү. Балаларда якын кешеләрнең хәленә керә белү (җәлләү, юату, кызгану) хисләрен тәрбияләү. | 21-30 ноябрь | **«Минем яраткан әнием» - күңел ачу чарасы**<br><br>Әниләргә бүләк әзерләү. |
| | **« КЫШ ЕЛ ФАСЫЛЫ» ПРОЕКТЫ** | | |
| Исәнме, кыш! | Кышкы табигатьнең үзенчәлекләре, кешеләренең шәһәрдәге эшчәнлекләре белән таныштыру. Кыш көне тормыш иминлеге нигезләрен үтәү. Кышкы табигать матурлыгын күрергә өйрәтү. Кышкы һава торышын күзәтү. | 1 - 2 декабрь | Төркемне кышка бизәү. Табигать почмагын мәгълүмат, уеннар һәм күрсәтмә материал белән тулыландыру. |
| Кыргый хайваннарның кышкы тормышы | Кайбер кыргый хайваннарны аерырыга һәм атарга өйрәтү; аларның үзенчәлекле якларын аерып карау күнекмәләрен формалаштыру; кыш көне урманда яшәүче хайваннарның яшәү рәвешләре һәм үз-үзләрен тотыш үзенчәлекләре белән таныштыру. | 5-9 декабрь | «Табигать» почмагы өчен дидактик һәм үстерелешле уеннар әзерләү |
| Кошлар – безнең дуслар! | Балаларның кышлаучы кошлар турында белемнәрен барлау. Экологик культура нигезләрен, кошларга карата аңлы һәм сакчыл караш формалаштыру .<br>Экоакцияләргә балаларны һәм аларның ата-аналарын җәлеп итү. Кошларга балалар бакчасы ишегалдында кышлар өчен шартлар тудыру. Балаларга кошларны кыш көне нәрсәләр белән ашатырга яраганлыгы хакында беренчел белемнәр бирү. | 12-16 декабрь | **«Кошлар ашханәсе» экоакциясе**<br>(кошларга җимлек әзерләү) |
| Чыршы һәм чыршы уенчыклары | Чыршы бизәү һәм чыршы тирәли җырлы-биюле уеннар уйнау кебек гаилә гореф-гадәтләрен искә төшерү һәм саклау. Икенчел материалдан чыршы уенчыклары һәм яңа ел чыршысын ясау. Табигать байлыгы – урманга карата җаваплы караш формалаштыру.<br>Яңа ел бәйрәмендә тере чыршылар куллануга карата сакчыл һәм рациональ караш тәрбияләү. Мәсьәләне хәл итүнең альтернатив вариантларын табу. | 19-23 декабрь | **«Яңа ел гирляндасы» күргәзмәсе**<br>(төрле материалдан әзерләнгән яңа ел уенчыкларын тәкъдим итү) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тиздән Яңа ел! | Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәменә кагылышлы барлык балалар эшчәнлеге төрләрен оештыру (уен, коммуникация, хезмәт, танып-белү, , музыкаль-сәнгати, уку)<br>Төркемдә бәйрәм атмосферасы, балаларда бәйрәм кәефе булдыру. | 26-30 декабрь | Төркемне бәйрәмгә бизәү. Якыннарга котлау һәм бүләкләр әзерләү.<br>Яңа ел бәйрәмен үткәрү. |

**РАСЛЫЙМ**

24 нче балалар бакчасы мөдире
__________________ А.А. Мәрдәнова
«____»___________2022 ел

**Казан шәһәре Вахитов районы МБМБУ « 24 нче  балалар бакчасы»**
**уртанчылар төркемендә тәрбия һәм белем бирү проектларын**
**тормышка ашыру буенча**
**2022-2023 уку елына перспектив-тематик план**

| **Тема** | **Эшчәнлек эчтәлеге** | **Вакыты** | **Йомгаклау чаралары** |
|---|---|---|---|
| **«МИН ҺӘМ БАКЧА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Мин балалар бакчасында!<br><br>Белем көне. | Балаларда мәктәпкә, китапка карата кызыксыну формалаштыру.  Үзара  дустанә мөнәсәбәт урнаштыруны дәвам итү. Балалар бакчасы белән иҗтимагый тирәлек буларак таныштыру (балалар бакчасы ишегалдындагы һәм төркемдәге үзгәрешләргә игътибар итү), балалар бакчасы хезмәткәрләренең эшчәнлеге хакында күзаллауларын киңәйтү (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, табиб, урам себерүче, пешекче) | 1-9 сентябрь | **«Белем бәйрәме» - күңел ачу чарасы**<br><br>**«Минем балалар бакчасы» - рәсем күргәзмәсе**. |
| Көз нигъмәтләре. | Балаларның көз турындагы күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигатьтәге үзгәрешләрнең үзара бәйләнешен күрергә өйрәтү (суытты – күбәләкләр юкка чыктылар, чәчәкләр сулды һ.б.), ел фасылына бәйле күзәтүләр алып бару.<br>Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре турында күзаллауны киңәйтү (шофер, комбайнер, тракторист).<br>Яшелчәләр, җиләк-җимешләр хакында белемнәрне тирәнәйтү. | 12-16 сентябрь | «Көзге ярминкә» - **күмәк ясалган кул эшләнмәләре күргәзмәсе** |
| Сак җәяүле атнасы | Балалар бакчасы ишегалдында һәм әйләнә – тирәсендә ориентлашырга өйрәтү, күзәтүчәнлекне үстерү. «Урам», «юл», «урам чаты», «җәмәгать транспорты тукталышы» терминары һәм урамда үзеңне имин тотуның элементарь кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.  Светофорның функцияләре, полицейскийның эшчәнлеге хакында белемнәрне барлау. Шәһәр транспорты төрләре, «җәяүлеләр кичүе», «җәмәгать транспорты тукталышы» юл билгеләре белән танышу. Җәмәгать трнаспортында үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре хакында мәгълүмат бирү. | 19-23 сентябрь | **Юл хәрәкәте иминлеге почмагын бизәү, өстәмә материаллар әзерләү**<br><br>Дидактик уеннар әзерләү |
| Балалар бакчасындагы һөнәрләр<br><br>Әбием белән бабам. | Балалар бакчасы хезмәткәрләренең эшчәнлеге хакында күзаллаулауны киңәйтү (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, табиб, урам себерүче, пешекче). Балаларда балалар бакчасына, аның хезмәткәрләренә карата  уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Хезмәткәрләргә рәсми рәвештә (исеме һәм әтисенең исеме белән) эндәшергә өйрәтү. | 26-30 сентябрь | Котлау гәҗите һәм бүләкләр әзерләү (күмәк эш) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Әби-бабайларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү. Исәнләшергә, рәхмәт, рәхим итегез сүзләрен кулланырга өйрәтү. Якын кешеләргә карата игътибар һәм мәхәббәт хисләрен тәрбияләү | | |
| **«ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ. КӨЗ ТӨСЛӘРЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Хайваннар дөньясында<br><br>4 октябрь – Бөтендөнья хайваннарны яклау көне | Балаларның хайваннар дөньясы төрлелеге хакында белемнәрен баету. Бәлә-казалар килеп чыкмасын өчен, хайваннар белән үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре хакында әңгәмә үткәрү.<br>Хайваннар, аларның күптөрлелеге һәм яшәү тирәлекләре турында белемнәре бирү. | 3-7 октябрь | Табигать почмагын уеннар, тематик альбомнар һәм презентация материаллары белән баету.<br>«Яхшылык кыл» **акциясендә катнашу** (сукбай хайваннар приюты өчен азык җыю) |
| Шәһәр парклары. Агачлар һәм куаклар. | Табигатьтәге һәм шәһәр паркларындагы үзгәрешләрне күрергә өйрәтү. Балаларның көз һәм көзге агачлар турында күзаллауларын киңәйтү (кешеләр киемендәге, балалар бакчасы ишегалдындагы, табигатьтәге, парк һәм аллеялардагы сезонлы үзгәрешләр).<br>Юлда үз-үзеңне имин тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Үсемлекләрне, кислород бүлеп чыгаручы бер чыганак буларак, сакларга өйрәтү. | 10-14 октябрь | «Көзге агачлар» **фотоэтюдлары** |
| **3 - 14 октябрь - ПЕДАГОГИК ПРОЦЕСС МОНИТОРИНГЫ** | | | |
| Табын күрке - икмәк | Балаларның икмәк һәм камыр ризыклары турында күзаллауларын киңәйтү. Икмәккә карата сакчыл караш; хезмәт кешеләренә (игенчеләр, пешекчеләр, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә) карата ихтирам һәм хөрмәт хисе тәрбияләү. | 17-21 октябрь | «Икмәк үткән юл» - **тематик альбомын ясау** |
| Түрдән уз – Алтын Көз! | Балаларның көз ел фасылы турында күзаллауларын киңәйтү. Көзге табигатьнең матурлыгын күрү сәләтләрен үстерү, һава торышын, терек һәм терек булмаган табигатьне күзәтү.<br>Балаларда бәйрәм кәефен булдыру өстендә эшләү, төркемне Сөмбелә бәйрәменә бизәү.<br>Үзара игътибарлы һәм дустанә мөнәсәбәт булдыру. | 24-38 октябрь | **«Сөмбелә» бәйрәме** |
| **«ВАТАН НӘРСӘДӘН БАШЛАНА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Халыклар бердәмлеге көне | Төркемне бәйрәмгә бизәү: дәүләт символикалары белән танышу. Балалар яшәгән шәһәр, урам исемнәрен искә төшерү.<br>Шәһәр иллюстрацияләрен игътибар белән карау һәм сорауларга җавап бирү күнекмәләрен үстерү.<br>Дуслык турында әңгәмә. | 31 октябрь-<br>4 ноябрь | «Этномәдәни региональ состав» **почмагын бизәү**<br><br>**УМК буенча уеннар** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Идел буенда яшәүче халыклар турында беренчел белемнәр бирү (татарлар, руслар, чувашлар, удмуртлар, марийлар һ.б.) | | |
| Нәрсә ул яхшылык?<br><br>13 ноябрь – Бөтендөнья яхшылык көне | Балаларда яхшы тон, этикет сыйфатларын формалаштыру. Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт хисләрен үстерү. Балаларны үзара ярдәмләшергә, яхшы эшләр эшләргә өйрәтү. Балаларда кешелеклелек, үзара ихтирам хисләрен тәрбияләү. | 7-11 ноябрь | **12 ноябрь – Песнәк көне (фотога төшерү)** «Кәгазь җыеп тапшыр һәм урманны саклап кал!» **экоакциясендә катнашу** |
| Сәламәт тәндә – сәламәт акыл | Балаларда сәламәт яшәү рәвеше алып бару турында кузаллау булдыру. Файдалы һәм зыянлы азык-төлек һәм гадәтләр турында белемнәр бирү. Балаларны үз сәламәтлекләре хакында уйларга һәм кайгыртырга өйрәтү. | 14-18 ноябрь | **«Без спорт белән дус!» - темасына күңелле стартлар, спорт ярышлары, чаралар үткәрү** |
| Мин һәм минем гаиләм.<br><br>Россиядә әниләр көне. | Гаилә, әнигә мәхәббәт темаларына карата барлык эшчәнлек төрләрен дә оештыру. Җенесләр турында күзаллау формалаштыру. Балаларны үз исемнәрен һәм гаилә әгъзаларының исемнәрен әйтергә өйрәтү. Балаларда якын кешеләрнең хәленә керә белү (җәлләү, юату, кызгану) хисләрен тәрбияләү. | 21-30 ноябрь | **«Минем яраткан әнием» - күңел ачу чарасы**<br><br>Әниләргә бүләк әзерләү. |
| | **« КЫШ ЕЛ ФАСЫЛЫ» ПРОЕКТЫ** | | |
| Исәнме, кыш! | Кышкы табигатьнең үзенчәлекләре, кешеләренең шәһәрдәге эшчәнлекләре белән таныштыру. Кыш көне тормыш иминлеге нигезләрен үтәү. Кышкы табигать матурлыгын күрергә өйрәтү. Кышкы һава торышын күзәтү. | 1 - 2 декабрь | Төркемне кышка бизәү. Табигать почмагын мәгълүмат, уеннар һәм күрсәтмә материал белән тулыландыру. |
| Кыргый хайваннарның кышкы тормышы | Кайбер кыргый хайваннарны аерырыга һәм атарга өйрәтү; аларның үзенчәлекле якларын аерып карау күнекмәләрен формалаштыру; кыш көне урманда яшәүче хайваннарның яшәү рәвешләре һәм үз-үзләрен тотыш үзенчәлекләре белән таныштыру. | 5-9 декабрь | **«Урман җәнлекләре» - панносын ясау** |
| Кошлар – безнең дуслар! | Балаларның кышлаучы кошлар турында белемнәрен барлау. Экологик культура нигезләрен, кошларга карата аңлы һәм сакчыл караш формалаштыру. Кошларга карата игътибарлы мөнәсәбәттә булу күнекмәләрен формалаштыру. | 12-16 декабрь | **«Кошлар ашханәсе» экоакциясе** (кошларга җимлек әзерләү) |
| Чыршы һәм чыршы уенчыклары | Чыршы бизәү һәм чыршы тирәли җырлы-биюле уеннар уйнау кебек гаилә гореф-гадәтләрен искә төшерү һәм саклау. Икенчел материалдан чыршы уенчыклары һәм яңа ел чыршысын ясау. Табигать байлыгы – урманга карата җаваплы караш формалаштыру. | 19-23 декабрь | **«Яңа ел гирляндасы» күргәзмәсе** (төрле материалдан әзерләнгән яңа ел уенчыкларын тәкъдим итү) |
| Тиздән Яңа ел! | Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәменә кагылышлы барлык балалар эшчәнлеге төрләрен оештыру (уен, | 26-30 декабрь | Төркемне бәйрәмгә бизәү. Оформление группы к празднику. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | коммуникация, хезмәт, танып-белү, , музыкаль-сәнгати, уку)<br>Төркемдә бәйрәм атмосферасы, балаларда бәйрәм кәефе булдыру.<br>Бәйрәм чарасы һәм кышкы каникуллар вакытында иминлек кагыйдәләре хакында сөйләшү. | | Якыннарга котлау һәм бүләкләр әзерләү.<br>**Яңа ел могҗизасы» бәйрәмен үткәрү** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ***1-8 гыйнвар каникул көннәре*** | | | |
| **«БЕЗНЕҢ ЯРАТКАН УЕННАР ҺӘМ УЕНЧЫКЛАР» ПРОЕКТЫ** | | | |
| 11 гыйнвар – Халыкара рәхмәт көне<br><br>Кышкы күңел ачу чаралары. | Балаларда яхшы гамәлләр кылу, якыннарына һәм дусларына булышу теләген формалаштыру.<br>Әйләнә- тирәдәгеләргә карата ихтирам һәм хөрмәт хисләрен тәрбияләү.<br><br>Милли гореф-гадәтләр белән таныштыруны дәвам итү. Кышкы спорт төрләре белән танышу; боз һәм кар белән тәҗрибәләр үткәрү; кышык табигать үзенчәлекләре белән танышу; авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүреше турында сөйләшү.<br>Балаларны, кыш көне урамда йөргәндә һәм уеннар уйнаганда, үз-үзләрен имин тоту кагыйдәләре белән таныштыру. | 9-13 гыйнвар | Әхлакый тәрбиягә юнәлдерелгән сюжетлы-рольле уеннар уйнау<br><br>Кышкы уеннар, халык уеннары, халык авыз иҗаты белән танышу.<br><br>**Бакча ишегалдында кардан ясалган фигуралар бәйгесен үткәрү.** |
| Уенчыклар дөньясында. | Балаларны күптөрле уенчыклар дөньсы һәм уенчыклар ясаганда куллана торган материал, чимал белән таныштыруны дәвам итү. Уенчыклардагы образ һәм алар ясалган материалның үзара бәйләнеше аша, җәмгыять үсешенә тәэсире турында балаларның күзаллауларын киңәйтү.  Балаларда бер-берләренә карата дустанә мөнәсәбәт, уенчыкларга карта сакчыл караш тәрбияләү. | 16-20 гыйнвар | **Ретро-уенчыклар күргәзмәсе**<br><br>Советлар союзы вакытындагы уеннар һәм уенчыклар. |
| Киемгә карап каршы алалар. | Балаларда киемнәрне тану һәм атау күнекмәләрен формалаштыру.<br>Тукыма үзлекләре, өс һәм аяк | 23-27 гыйнвар | Предметлы-үстерелешле тирәлекне оештыру: |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Өс киемнәре һәм аяк киемнәре. | киемнәренең килеп чыгу тарихлары белән таныштыру. Киемнәрнең атамаларын өйрәнү аша сүзлек запасын арттыру.<br>Балаларны гардеробтагы киемнәрен пөхтә итеп тотарга өйрәтү. Зәвык һәм пөхтәлек тәрбияләү. | | төркемдәге почмакларны бизәү.<br><br>**«Подиум» - ата-аналар һәм балаларның уртак иҗат җимешләрен тәкъдим итү** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **«ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ КӨНЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Мин - дөньяның бер кешесе. | Баланың шәхес булуы хакында фикерен формалаштыру, үзенә карата уңай бәяләмә булдырырга булышу. Малайлар һәм кызларның тышкы кыяфәтләрендәге аермалы яклар, җенесләр хакында беренчел күзаллауларын формалаштыру. Балаларны әйләнә-тирәдәге предметлар белән таныштыруны дәвам итү. Җиһаз, транспорт, кием, бина, балалар, зурлар һ.б. сүзләрнең балаларның сөйләм телендә актив кулланылышына ирешү. | 30 гыйнвар -3 февраль | Кешенең тән төзелеше, организм системасының функцияләре хакында әңгәмәләр үткәрү.<br>Әлеге тематикага карата презентацияләр тәкъдим итү. |
| Һөнәрләр һәм эш кораллары. | Һөнәрләр һәм эш кораллары турында белемнәрне киңәйтү. Билгеле бер һөнәр иясенең нинди эш кораллары, атрибутлар кулланганы белән танышу.<br>Ата-аналарның нинди өлкәдә хезмәт куюларын, нинди һөнәр ияләре булуларын әйтә белү күнекмәләрен ныгыту. | 6-10 февраль | **Стенгазета:**<br>«Һөнәрле – үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс!»<br><br>«Кибеттә», «Тегүче» һ.б. уеннар. |
| Туган тел атналыгы. | Балаларның туган тел турында күзаллауларын киңәйтү һәм тирәнәйтү. М.Җәлил шигырьләрен яттан өйрәнү, туган телдә матур әдәбият уку.<br>Балаларны танылган шагыйрь һәм язучылар белән таныштыру. Туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләү. | 13-17 февраль | **«Кызыл ромашка» - Муса Җәлил шигырьләрен укучылар арасында бәйге.**<br><br>Балалар язучылары һәм шагыйрьләре белән очрашулар үткәрү. |
| Ватанны саклаучылар көне | Бөек Ватан сугышы елларында Россия армиясенең мөһим роль уйнавы хакында күзаллауларын киңәйтү. Ватанпарвәрлек һәм туган илгә карата мәхәббәт тәрбияләү. Гаиләдә әти ролен популярлаштыру. Малайларга, әти, бабайларга бүләкләр әзерләү.<br><br>. | 20-24 февраль | **Күңелле стартлар -** «Безнең әти – шәп әти!» |
| **«ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ. ЯЗ» ПРОЕКТЫ** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Май чабу бәйрәме | Халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләре белән таныштыру. Халык бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләрена карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. | 27 февраль - 3 март | «Май чабу бәйрәме» - **күңел ачу чарасы**<br>Халык уеннары, бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре. |
| «Яратам сине, әнием!»<br>8 март – Халыкара хатын-кызлар көне. | Гаилә, әнигә һәм әбиләргә карата мәхәббәт темасына кагылышлы барлык эшчәнлек төрләрен дә оештырырга : уен, коммуникация, хезмәт, танып-белү, уку, музыкаль – сәнгати һ.б.<br>Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә карата хөрмәт хисе тәрбияләү. | 6-10 март | Бүләкләр әзерләү.<br>Бәйрәмгә төркемне бизәү.<br>Котлау гәҗитен бастырып чыгару.<br>**«Өйләр ямьле булсын өчен – әни кирәк» - Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган бәйрәм** |
| Милли уенчык. | Мили уенчык хакында күзаллауны киңәйтү ( матрешка һ.б.)<br>Милли уенчыклар, милли көй-җырлар аша халык иҗаты белән таныштыру. Халык авз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.<br>Балаларның эшчәнлек төрләрен оештырганда фольклор үрнәкләрен куллану. | 13-17 март | Халык кул эшләнмәләре күргәзмәсен оештыру. |
| Нәүрүз. | Яз турында күзаллауны киңәйтү.<br>Табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. Язгы табигатьнең матурлыгын күрергә һәм тоярга өйрәтү.<br>Балаларга төрле сәнгать эшчәнлекләрендә яздан алган тәэсирләрен чагылдырырга булышу.<br>Яз көне табигатьтәге үзгәрешләр хакында күзаллауны формалаштыру. Татарстан җирлегендәге елгалар хакында белемнәрне киңәйтү. | 20-24 март | «Ләйсән яңгыр» балалар иҗаты күргәзмәсен оештыру.<br>**«Нәүрүз» - күңел ачу чарасы** |
| Язгы ташкыннар | Табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү. Терек һәм терек булмаган табигатьтәге үзгәрешләрнең бәйләнешен билгеләү. Җәнлекләр һәм үсемлекләр дөньясындагы үзгәрешләргә игътибар итү. Экологик почмакны бизәү, материаллар өстәү. Күчмә кошларны каршы алырга әзерлек. Урманда һәм балалар бакчасы ишегалдында үзеңне имин тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Кошларга карата сакчыл караш тәрбияләү. | 27-31 март | **«Тәрәзә төбе – безнең бакчабыз» - композициясен булдыру.**<br>Тәҗрибәләр һәм күзәтү эшчәнлеген оештыру (картотека). |
| **«БАЛАЧАК КИТАПХАНӘСЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Гаҗәеп дөнья – театр | Балаларга театр һәм аларның төрләре турында беренчел белемнәр бирү. Төрле | 3-7 апрель | «Театраль һөнәрләр» - диалог – әңгәмәсе. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Көлке көне | театр жанрларына, театраль һөнәрләргә карата кызыксыну уяту.<br>Балаларны актер, режиссер, рәссам, композитор һөнәрләре белән таныштыру Яңалыкка омтылу теләген тәрбияләү.<br>Балаларда юмор хисен, шаяруларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | | «Казан театрлары» - презентациясе.<br><br>**Туган телдә спектакльләр кую** |
| Космос серләре | Планеталар, йолдызлар, галактика, космосны үзләштерүдә зур эшләр башкарган кешеләр турында күзаллауны киңәйтүне дәвам итү.<br>Астрономия фәне хакында беренчел белемнәр бирү. | 10-14 апрель | Һава белән тәҗрибәләр үткәрү.<br><br>**«Космоска сәяхәт» - балалар иҗаты күргәзмәсе.** |
| **17 -28 АПРЕЛЬ - ПЕДАГОГИК ПРОЦЕСС МОНИТОРИНГЫ** | | | |
| Халыкара җир көне | Җир шарының экологик проблемалары хакында белемнәрне киңәйтү: янгыннар, су басулар, су һәм һаваның пычрануы.<br>Планетабызының табигать ресурсларына карата рациональ һәм сакчыл караш тәрбияләү. | 17-21 апрель | **Экологик бәйрәм - «Җир көне»**<br><br>Темага кагылышлы презентацияләр, күргәзмәләр |
| Г.Тукайның туган көне | Татар халкының бөек шагыйре – Габдулла Тукайның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.<br>Татар шагыйрьләре һәм язучыларының әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү. | 24-28 апрель | **«Тукай иленә сәяхәт» - әдәби-музыкаль кичәсе** |
| **«ЧӘЧӘКЛЕ БАКЧА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Чәчәкле май<br><br>«9 май – Җиңү көне» | Бакчада үсә торган яшелчә һәм җиләк-җимешләр турында белемнәрне киңәйтү. Әйләнә-тирә дөньяга карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>Балаларны Бөек Ватан сугышы, Җиңү көне тарихы белән таныштыру. Үз илең, сугыш геройлары өчен горурлык хисләре тәрбияләү. | 4-12 май | Төркемне бәйрәмгә бизәү.<br>Ветераннарга бүләкләр әзерләү.<br>**«Җиңү иртәсе» - ветераннар өчен бәйрәм концерты оештыру** |
| 15 май –Халыкара гаилә көне | Балаларның традицион гаилә турында күзаллауларын формалаштыру. Гаилә кыйммәтләрен тәрбияләү.<br>Гаиләдәге кешеләр һәм аларның функцияләре турында әңгәмәләр үткәрү. | 15-19 май | «Безнең гаилә», «Безнең өй» уеннары (УМК).<br><br>**«Минем гаиләм» - төркемнәрдә күңел ачу чарасы.** |
| Сәламәт тәндә – сәламәт акыл! | Кеше өчен кояш, һава, суның нинди мөһим роль уйнаганлыгы турында белемнәрне киңәйтү. Сәламәт яшәү рәвешенә, рациональ туклануга карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.<br>Дөрес итеп чыныгу кагыйдәләре, чыныгу төрләре һәм әлеге процедураларның файдасы хакында белемнәрне киңәйтү.<br>Балаларда үзләренең иминлеге өчен җаваплылык хисен формалаштыру. | 22-26 май | Балалар өчен имин җәйге ял оештыру, балаларны чыныктыру, җәй көне туклану үзенчәлекләре темаларына **ата-аналар өчен консультацияләр**<br><br>**«Хәрәкәттә-бәрәкәт» -** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | **Сәламәтлекне ныгытуга юнәлдерелгән күңел ачу чарасы.** |
| «Дуслык» | Балаларны Татарстанда яшәүче халыклар белән таныштыруны дәвам итү.<br>Барлык милләт вәкилләренә карата да хөрмәт һәм ихтирамлы мөнсәсбәт тәрбияләү.<br>Идел буе халыкларының җыр-биюләре, ризыклары белән таныштыру. .. | 29-31 май | **«Дуслык» - халык мәдәнияте фестивале** |

**РАСЛЫЙМ**

24 нче балалар бакчасы мөдире
__________________ А.А. Мәрдәнова
«____»___________2022 ел

**Казан шәһәре Вахитов районы МБМБУ « 24 нче балалар бакчасы»**
**мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбия һәм белем бирү проектларын**
**тормышка ашыру буенча**
**2022-2023 уку елына перспектив-тематик план**

| Тема | Эшчәнлек эчтәлеге | Вакыты | Йомгаклау чаралары |
|---|---|---|---|
| | **«МИН ҺӘМ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» ПРОЕКТЫ** | | |
| Мин балалар бакчасында! Белем көне. | Балаларда мәктәпкә, китапка,укуга карата кызыксыну формалаштыру. Балаларның мәктәп турындагы белемнәрен ныгыту, ни өчен укырга кирәклеге хакында әңгәмәләр үткәрү, мәктәп кирәк-яраклары белән танышуны дәвам итү. Укытучы һәм укучы шәхесе хакында уңай күзаллау формалаштыру.<br>Балалар бакчасында үзеңне тоту кагыйдәләре хакында белемнәрен ныгыту. | 1-9 сентябрь | **«Белем бәйрәме» - күңел ачу чарасы**<br><br>**«Минем балалар бакчасы» - рәсем күргәзмәсе**. |
| Көз нигъмәтләре. | Балаларның яшелчә һәм җиләк-җимешләр, бакчаны кышка әзерләү хакындагы күзаллауларын киңәйтү.<br>Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре һөнәрләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>Авыл хуҗалыгында эшләүче кешеләрнең хезмәтенә карата хөрмәт хисен тәрбияләү. Әйләнә-тирәдәге матурлыкны күрә белү хисен, зурларга кышка җиләк-җимешләрне әзерләшү теләген тәрбияләү. Бакчадагы уңышны җыю. | 12-16 сентябрь | **«Көзге ярминкә» күргәзмәсе**<br><br>«Бакчадагы уңыш» темасына кагылышлы презентацион материал һәм әсбаплар үзерләү |
| Сак җәяүле атнасы | Юл хәрәкәте, урам турында белемнәрне системага салу. Юл билгеләре белән танышуны дәвам итү. Балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү мөһимлеген аңлап, кабул итүләренә ирешү. ЮХИДИ хезмәткәрләреең эшчәнлеге хакында күзаллауларын киңәйтү. Урамда һәм җәмәгать транспортында үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү. | 19-23 сентябрь | **Юл хәрәкәте иминлеге почмагын бизәү.** Юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен үтәүгә кагылышлы буклетлар, дидактик уеннар өстәмә материаллар әзерләү |
| | Балалар бакчасы хезмәткәрләренең эшчәнлеге хакында күзаллауны киңәйтү (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, табиб, урам себерүче, пешекче). Балаларда балалар | 26-30 сентябрь | **Балалар бакчасы хезмәткәрләренә видеоязма рәвешендә котлау әзерләү.** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Балалар бакчасындагы һөнәрләр<br><br>Халыкара өлкәннәр көне | бакчасына, аның хезмәткәрләренә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру.<br>Хезмәткәрләргә рәсми рәвештә (исеме һәм әтисенең исеме белән) эндәшергә өйрәтү.<br>Гаиләнең җәмгыятьнең иҗтимагый бер төркеме булуы хакында күзаллауны булдыру.<br>Әби-бабайларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү. Исәнләшергә, рәхмәт, рәхим итегез сүзләрен кулланырга өйрәтү. Якын кешеләргә карата игътибар һәм мәхәббәт хисләрен тәрбияләү. | | **Әби-бабайларга котлау тәбрикләмәләре әзерләргә.** |
| **«ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ. КӨЗ ТӨСЛӘРЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Хайваннар дөньясында<br><br>4 октябрь – Бөтендөнья хайваннарны яклау көне | Балаларның хайваннар дөньясы төрлелеге хакында белемнәрен баету. Бәлә-казалар килеп чыкмасын өчен, хайваннар белән үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре хакында әңгәмә үткәрү.<br>Хайваннар, аларның күптөрлелеге һәм яшәү тирәлекләре турында белемнәре бирү. | 3-7 октябрь | «Яхшылык кыл» **акциясендә катнашу** (сукбай хайваннар приюты өчен азык җыю)<br>**«Хайваннар дөньясында» темасына презентация әзерләү** |
| Шәһәр парклары. Агачлар һәм куаклар. | Балаларның көз турында күзаллауларын киңәйтү (кешеләр киемендәге, балалар бакчасы ишегалдындагы, табигатьтәге, парк һәм аллеялардагы сезонлы үзгәрешләр) уңыш җыю вакыты, җиләк-җимешләр, гөмбәләр, табигатьтә үзеңне имин тоту кагыйдәләре.<br>Экосистемалар, экологик акцияләр хакында беренчел күзаллаулар формалаштыру.<br>Көзге табигать матурлыгын күрү, һава торышын күзәтү, көзге күренешләрне рәсемгә төшерү теләген булдыруга шартлар тудыру. | 10-14 октябрь | «Көз - рәссам» **фотоэтюдлары**<br><br>Табигать почмагын үстерелешле уеннар, күрсәтмә материал белән тулыландыру. |
| **3 - 14 октябрь - ПЕДАГОГИК ПРОЦЕСС МОНИТОРИНГЫ** | | | |
| Икмәк үткән юл | Балаларның икмәк һәм камыр ризыклары турында күзаллауларын киңәйтү. Икмәккә карата сакчыл караш; хезмәт кешеләренә (игенчеләр, пешекчеләр, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә) карата ихтирам һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.<br>Сәнгать әсәрләрендә (шигырь, рәсем, музыка) көзне гәүдәләндерү үзенчәлекләре белән таныштыру. | 17-21 октябрь | **Темаларына презентацияләр әзерләү** «Игенчеләр», «Авыл хуҗалыгы транспорты», «Алтын башак сәяхәте», «Камыр ризыклары» **темаларына презентацияләр әзерләү** |
| Безнең бакчада көз | Ел фасыллары хакында белемнәрен арттыру. Табигать күренешләренә карата кызыксыну формалаштыруга шартлар тудыру (яңгыр, җил, болытлы күк, һ.б.)<br>Зур булмаган хикәяләр төзү күнекмәләрен үстерү; халык сынамышлары, мәкаль һәм | 24-28 октябрь | **«Көзге көйләр» - музыкаль күңел ачу чарасы** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әйтемнәре белән таныштыру. Көз турында шигырьләр һәм җырлар өйрәнү. | | |
| **«ВАТАН НӘРСӘДӘН БАШЛАНА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Халыклар бердәмлеге көне | Шәһәр иллюстрацияләрен, дәүләт символикаларын игътибар белән карау күнекмәләрен үстерү. Халыклар арасындагы дуслык турында әңгәмәләр. Идел буенда яшәүче халыклар турында беренчел белемнәр бирү (татарлар, руслар,чувашлар, удмуртлар, марийлар h.б.) Ватанпарвәрлек, башка халыкларга карата толерант мөнәсәбәнт тәрбияләү. | 31 октябрь- 4 ноябрь | «Этномәдәни региональ состав» **почмагын бизәү**<br><br>УМК буенча уеннарны тулыландыру |
| Нәрсә ул яхшылык?<br><br>13 ноябрь – Бөтендөнья яхшылык көне | Балаларда яхшы тон, этикет сыйфатларын формалаштыру. Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт хисләрен үстерү. Үзара ярдәмләшергә, яхшы эшләр эшләргә өйрәтү; кешелеклелек, үзара ихтирам хисләрен тәрбияләү. Волонтерлар, аларның башкарган эшләре турында күзаллауны булдыру. | 7-11 ноябрь | **12 ноябрь – Песнәк көне (фотога төшерү)** «Кәгазь җыеп тапшыр һәм урманны саклап кал!» **экоакциясендә катнашу** |
| Сәламәт тәндә – сәламәт акыл | Балаларда сәламәт яшәү рәвеше алып бару турында кузаллау булдыру. Балаларга файдалы һәм зыянлы азык-төлек һәм гадәтләр турында белемнәр бирү. Үз сәламәтлекләре хакында уйларга һәм кайгыртырга өйрәтү. Спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру. | 14-18 ноябрь | **«Без спорт белән дус!» -** темасына күңелле стартлар, спорт ярышлары, чаралар үткәрү |
| Мин һәм минем гаиләм.<br><br>Россиядә әниләр көне. | Гаилә, әнигә мәхәббәт темаларына карата барлык эшчәнлек төрләрен дә оештыру. Җенесләр турында күзаллау формалаштыру. Балаларны үз исемнәрен һәм гаилә әгъзаларының исемнәрен әйтергә өйрәтү. Гаилә әгъзаларына, әнигә карата хөрмәт һәм мәхәбәт хисләрен тәрбияләү. | 21-30 ноябрь | «Әни – иң кадерле кеше» - котлау гәҗитен чыгару. **Әниләр көненә күңел ачу чарасы.** |
| **« КЫШ ЕЛ ФАСЫЛЫ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Исәнме, кыш! | Балаларның кыш турында белемнәрен, кыш көне тормыш иминлеге нигезләрен үтәү турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать арасындагы бәйләнешләр хакында сөйләшү. Кар һәм боз үзлекләре турында белемнәрен ныгыту. | 1 - 2 декабрь | Төркемнәрне кышка бизәү. «Кышкы бизәкләр» - балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Кыргый хайваннарның кышкы тормышы | Кыргый хайваннарны аерырга һәм исемнәре белән атарга өйрәтү. Аларның үзенчәлекле якларын аерып карау күнекмәләрен формалаштыру; кыш көне урманда яшәүче хайваннарның яшәү рәвешләре һәм үз-үзләрен тотыш үзенчәлекләре белән таныштыру. Кыш көне җәнлекләргә булышу, ярдәм итү теләкләрен тәрбияләү. | 5-9 декабрь | **Балалар өчен җәнлекләр турында презентацияләр әзерләү**<br><br>Табигать почмагын темага туры килә торган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | материал белән тулыландыру. |
| Кошлар – безнең дуслар! | Терек табигатькә карата сакчыл караш, хөрмәт һәм ихтирам белән карау хисләрен тәрбияләү. Хәзерге дөньяда экологик культура турында күзаллау формалаштыру. Балалар һәм ата-аналар белән берлектә экоакцияләрдә катнашу, кошларга кышны чыгарга ярдәм итү, бакча ишегалдында җимлекләр урнаштыру. Кошларга кышын нәрсәләр ашатырга мөмкин булганлыгы хакында сөйләшү. | 12-16 декабрь | **«Кошлар ашханәсе» экоакциясендә катнашу** (кошларга җимлек әзерләү) |
| Чыршы һәм чыршы уенчыклары | Чыршы бизәү һәм чыршы тирәли җырлы-биюле уеннар уйнау кебек гаилә гореф-гадәтләрен искә төшерү һәм саклау. Икенчел материалдан чыршы уенчыклары һәм яңа ел чыршысын ясау. | 19-23 декабрь | **Яңа ел гирляндасы» күргәзмәсе** (төрле материалдан әзерләнгән яңа ел уенчыкларын тәкъдим итү) |
| Могҗизалар вакыты! | Яңа ел бәйрәменең килеп чыгу тарихы белән танышу. Төрле илләрдә яңа ел бәйрәм итү гореф-гадәтләре белән танышу. Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәме темасына кагылышлы барлык балалар эшчәнлеге төрләрен оештыру. | 26-30 декабрь | Төркемне бәйрәмгә бизәү, якыннарга бүләкләр һәм котлаулар әзерләү. **«Яңа ел тамашасы» бәйрәме** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ***1-8 гыйнвар каникул көннәре*** | | | |
| **«БЕЗНЕҢ ЯРАТКАН УЕННАР ҺӘМ УЕНЧЫКЛАР» ПРОЕКТЫ** | | | |
| 11 гыйнвар – Халыкара рәхмәт көне<br><br>Кышкы күңел ачу чаралары. | Балаларда яхшы гамәлләр кылу, якыннарына һәм дусларына булышу теләген формалаштыру.<br>Әйләнә- тирәдәгеләргә карата ихтирам һәм хөрмәт хисләрен тәрбияләү.<br><br>Милли гореф-гадәтләр белән таныштыруны дәвам итү. Кышкы спорт төрләре белән танышу; боз һәм кар белән тәҗрибәләр үткәрү; кышкы табигать үзенчәлекләре белән танышу; авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүреше турында сөйләшү. Балаларны, кыш көне урамда йөргәндә һәм уеннар уйнаганда, үз-үзләрен имин тоту кагыйдәләре белән таныштыру. | 9-13 гыйнвар | Әхлакый тәрбиягә юнәлдерелгән сюжетлы-рольле уеннар уйнау<br><br>Кышкы уеннар, халык уеннары, халык авыз иҗаты белән танышу.<br><br>**Бакча ишегалдында кардан ясалган фигуралар бәйгесен үткәрү.** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Уенчыклар дөньясында | Балаларны күптөрле уенчыклар дөньсы һәм уенчыклар ясаганда куллана торган материал, чимал белән таныштыруны дәвам итү. Уенчыклардагы образ һәм алар ясалган материалның үзара бәйләнеше аша, җәмгыять үсешенә тәэсире турында балаларның күзаллауларын киңәйтү. Балаларда бер-берләренә карата дустанә мөнәсәбәт, уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү. | 16-20 гыйнвар | **Кулдан ясалган уенчыклар күргәзмәсе.** (ата-аналар белән күмәк иҗади эш) |
| Кием | Балаларда киемнәрне тану һәм атау күнекмәләрен формалаштыру. Тукыма үзлекләре, өс һәм аяк киемнәренең килеп чыгу тарихлары белән таныштыру. Киемнәрнең атамаларын өйрәнү аша сүзлек запасын арттыру. Балаларны гардеробтагы киемнәрен пөхтә итеп тотарга өйрәтү | 23-27 гыйнвар | Предметлы-үстерелешле тирәлек – балалар өчен киемнәр почмагы әзерләү. **УМК буенча үстерелешле уеннар һәм уен әсбаплары әзерләү** ( «Киемнәр», «Кием кибете», «Ателье» уеннары) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **«ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ КӨНЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Мин дөньяның бер кешесе. | Баланың шәхес булуы хакында фикерен формалаштыру, үзенә карата уңай бәяләмә булдырырга булышу. Малайлар һәм кызларның тышкы кыяфәтләрендәге аермалы яклар, җенесләр хакында беренчел күзаллауларын формалаштыру. Балаларны әйләнә-тирәдәге предметлар белән таныштыруны дәвам итү. Җиһаз, транспорт, кием, бина, балалар, зурлар һ.б. сүзләрнең балаларның сөйләм телендә актив кулланылышына ирешү. | 30 гыйнвар-3 февраль | Кешенең тән төзелеше, организм системасының функцияләре хакында әңгәмәләр үткәрү. **«Мин - кеше» викторинасы** |
| Һөнәрләр һәм эш кораллары. | Һөнәрләр һәм эш кораллары турында белемнәрне киңәйтү. Билгеле бер һөнәр иясенең нинди эш кораллары, атрибутлар кулланганы белән танышу. Ата-аналарның нинди өлкәдә хезмәт куюларын, нинди һөнәр ияләре булуларын әйтә белү күнекмәләрен ныгыту. Хезмәт кешеләренә карата хөрмәт хисе тәрбияләү. | 6-10 февраль | **Стенгазета:** «Һөнәрле – үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс!» УМК буенча уеннар «Кибет», «Ателье», «Матурлык салоны», «Шифаханә» һ.б. |
| Туган тел атналыгы | Балаларның туган тел турында күзаллауларын киңәйтү һәм тирәнәйтү. М.Җәлил шигырьләрен яттан өйрәнү, туган телдә матур әдәбият уку. | 13-17 февраль | **«Кызыл ромашка» - Муса Җәлил шигырьләрен укучылар арасында бәйге.** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Балаларны танылган шагыйрь һәм язучылар белән таныштыру. Туган телгә карата мәхәббәт һәм кызыксыну тәрбияләү. | | Балалар язучылары һәм шагыйрьләре белән очрашулар. |
| Ватанны саклаучылар көне | Бөек Ватан сугышы елларында Россия армиясенең мөһим роле хакында күзаллауларын киңәйтү. Ватанпарвәрлек һәм туган илгә карата мәхәббәт тәрбияләү. Гаиләдә әти ролен популярлаштыру. Малайларга, әти, бабайларга бүләкләр әзерләү. | 20-24 февраль | **«Әти – минем дустым» - күңелле стартлар** |
| **«ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ. ЯЗ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Май чабу бәйрәме | Халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләре белән таныштыру. Халык бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләрена карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. | 27 февраль - 3 март | «Май чабу бәйрәме» - к**үңел ачу чарасы**<br>Халык уеннары, бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре. |
| «Әниләр – өйнең яме!»<br>8 март – Халыкара хатын-кызлар көне. | Гаилә, әнигә һәм әбиләргә карата мәхәббәт темасына кагылышлы барлык эшчәнлек төрләрен дә оештыру: уен, коммуникация, хезмәт, танып-белү, уку, музыкаль – сәнгати һ.б.<br>Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә карата хөрмәт хисе тәрбияләү. | 6-10 март | Бүләкләр әзерләү. Бәйрәмгә төркемне бизәү. Котлау гәҗитен бастырып чыгару.<br>**«Иң кадерле, әнием!» - Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган бәйрәм үткәрү** |
| Милли уенчык. | Мили уенчык хакында күзаллауны киңәйтү ( матрешка һ.б.)<br>Милли уенчыклар, милли көй-җырлар аша халык иҗаты белән таныштыру. Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның эшчәнлек төрләрен оештырганда фольклор үрнәкләрен куллану. | 13-17 март | Халык кул эшләнмәләре күргәзмәсен оештыру. |
| Нәүрүз. | Яз турында күзаллауны киңәйтү. Табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. Язгы табигатьнең матурлыгын күрергә һәм тоярга өйрәтү.<br>Балаларга төрле сәнгать эшчәнлекләрендә яздан алган тәэсирләрен чагылдырырга булышу.<br>Яз көне табигатьтәге үзгәрешләр хакында күзаллауны формалаштыру. Татарстан җирлегендәге елгалар хакында белемнәрне киңәйтү. | 20-24 март | «Ләйсән яңгыр» балалар иҗаты күргәзмәсен оештыру.<br>**«Нәүрүз» - күңел ачу чарасы** |
| Язгы ташкыннар | Табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү. Терек һәм терек булмаган табигатьтәге үзгәрешләрнең бәйләнешен билгеләү. | 27-31 март | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Җәнлекләр һәм үсемлекләр дөньясындагы үзгәрешләргә игътибар итү. Экологик почмакны бизәү, материаллар өстәү. Күчмә кошларны каршы алырга әзерлек. Урманда һәм балалар бакчасы ишегалдында үзеңне имин тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Кошларга карата сакчыл караш тәрбияләү. | | **«Тәрәзә төбе – безнең бакчабыз» - композициясен булдыру.**<br>Тәҗрибәләр һәм күзәтү эшчәнлеген оештыру (картотека). |
| **«БАЛАЧАК КИТАПХАНӘСЕ» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Гаҗәеп дөнья – театр<br>Көлке көне | Балаларга театр һәм аларның төрләре турында беренчел белемнәр бирү. Төрле театр жанрларына, театраль һөнәрләргә карата кызыксыну уяту.<br>Балаларны актер, режиссер, рәссам, композитор һөнәрләре белән таныштыру Яңалыкка омтылу теләгенн тәрбияләү. Балаларда юмор хисен, шаяруларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | 3-7 апрель | «Театраль һөнәрләр» - диалог – әңгәмәсе.<br>«Казан театрлары» - презентациясе.<br>**Туган телдә спектакльләр кую** |
| Космос серләре | Планеталар, йолдызлар, галактика, космосны үзләштерүдә зур эшләр башкарган Рәсәй кешеләре турында күзаллауны киңәйтүне дәвам итү. Астрономия фәне хакында беренчел белемнәр бирү. | 10-14 апрель | Һава белән тәҗрибәләр үткәрү.<br>**«Космоска сәяхәт» - балалар иҗаты күргәзмәсе.** |
| **17 -28 АПРЕЛЬ - ПЕДАГОГИК ПРОЦЕСС МОНИТОРИНГЫ** | | | |
| Халыкара җир көне | Җир шарының экологик проблемалары хакында белемнәрне киңәйтү: янгыннар, су басулар, су һәм һаваның пычрануы, зур территорияләрдә урманнар киселеше, табигать бәла-казалары. Планетабызының табигать ресурсларына карата рациональ һәм сакчыл караш тәрбияләү. | 17-21 апрель | **Экологик бәйрәм - «Җир көне»**<br>Темага кагылышлы презентацияләр, күргәзмәләр |
| Г.Тукайның туган көне | Татар халкының бөек шагыйре – Габдулла Тукайның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.<br>Татар шагыйрьләре һәм язучыларының әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү. | 24-28 апрель | **«Тукай иленә сәяхәт» - әдәби-музыкаль кичәсе** |
| **«ЧӘЧӘКЛЕ БАКЧА» ПРОЕКТЫ** | | | |
| Чәчәкле май<br>«9 май – Җиңү көне» | Бакчада үсә торган яшелчә һәм җиләк-җимешләр турында белемнәрне киңәйтү. Әйләнә-тирә дөньяга карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>Балаларны Бөек Ватан сугышы, Җиңү көне тарихы белән таныштыру. Үз илең, сугыш геройлары өчен горурлык хисләре тәрбияләү. | 4-12 май | Төркемне бәйрәмгә бизәү.<br>Ветераннарга бүләкләр әзерләү.<br>**«Җиңү иртәсе» - ветераннар өчен бәйрәм концерты оештыру** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 май –Халыкара гаилә көне | Балаларның традицион гаилә турында күзаллауларын формалаштыру. Гаилә кыйммәтләрен тәрбияләү.<br>Гаиләдәге кешеләр һәм аларның функцияләре турында әңгәмәләр үткәрү. | 15-19 май | «Безнең гаилә», «Безнең өй» уеннары (УМК).<br><br>**«Минем гаилә» - төркемнәрдә күңел ачу чарасы.** |
| Сәламәт тәндә – сәламәт акыл! | Кеше өчен кояш, һава, суның нинди мөһим роль уйнаганлыгы турында белемнәрне киңәйтү. Сәламәт яшәү рәвешенә, рациональ туклануга карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.<br>Дөрес итеп чыныгу кагыйдәләре, чыныгу төрләре һәм әлеге процедураларның файдасы хакында белемнәрне киңәйтү. Балаларда үзләренең иминлеге өчен җаваплылык хисен формалаштыру. | 22-26 май | Балалар өчен имин җәйге ял оештыру, балаларны чыныктыру, җәй көне туклану үзенчәлекләре темаларына **ата-аналар өчен консультацияләр**<br><br>**«Хәрәкәттә-бәрәкәт» - сәламәтлекне ныгытуга юнәлдерелгән күңел ачу чарасы.** |
| Сау бул, бакчабыз! | Мәктәп, мәктәптә үзеңне тоту кагыйдәләре, укытучылар, уку әсбаплары хакында булган белемнәре ныгыту. Укытучыларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү. | 29-31 май | **«Сау бул, балалар бакчасы! Исәнме, мәктәп» - чыгарылыш кичәсе.** |